Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының
Сәрдекбаш авыл җирлеге башлыгы

**КАРАРЫ**

«12» ноябрь, 2025 ел № 6

**Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге Яңа Сәрдек авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2025 елның 26 ноябрендә 09 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлегенең Яңа Сәрдек авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Яңа Сәрдек авылы, Яңа урам, 2а адресында урнашкан авыл клубы бинасында уздырырга.

2. 2025 елның 26 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлегенең Яңа Сәрдек авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Яңа Сәрдек авылы, Яңа урам, 2а адресында урнашкан авыл клубы бинасында уздырырга.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 2026 елда Кукмара муниципаль районының Сәрдекбаш авыл җирлеге Яңа Сәрдек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 85 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

- урамнарны яктырту җайланмасы;

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын,

- коеларны төзекләндерү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү;

- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту;

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

- янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын төзү, ремонтлау;

- мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр)булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүлү.

6. Сәрдекбаш авылы башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

7. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

8. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сәрдекбаш авыл
җирлеге башлыгы И.М. Нәбиев